**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422626 с. Кирби,
ул. Лесная, д.1
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422626 Хәерби авылы,
Урман урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-38-16

**№ 8** **2019 елның 23 апрелennән**

# К А Р А Р

**“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы төстә тәкъдим ителүче хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга, 1996 елның 12 гыйнварыннан №8-ФЗ “Җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнварыннан №32 “2019 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында”гы карарына, 2004 елның 28 июленнән №45-ЗРТ “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы ТР Законына, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2007 елның 18 маеннан №196 “Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында”гы Федераль законны гамәлгә ашыру буенча чаралар турында”гы карарына, “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставынаярашлы төстә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегендәҗирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенә ярашлы төстә тәкъдим ителүче хезмәтләр бәясен 1нче һәм 2нче кушымталарга ярашлы төстә 2019 елның 1 февраленнән 5946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Лаеш муниципаль районы рәсми сайтының Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

**Җитәкче** **М.Д.Минбаева**